МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Пушкина, д. 66/33, г. Казань, 420015

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ
Пушкин ур., 66/33нче йорт, Казан ш., 420015

Тел.: (843) 264-74-01, факс: (843) 292-07-26. mkrt@tatar.ru, mincult.tatarstan.ru

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

**13.03.2017** **№ 217 од**

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында

«Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү турында» 17 июль, 2009 ел, 172-ФЗ номерлы Федераль законга, «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү турында» 26 февраль, 2010 ел, 96нчы номерлы Россия Федерациясе карарына һәм «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 24.12.2009 ел, 883нче номерлы карарына нигезләнеп

**БОЕРАМ:**

1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрүнең теркәлгән тәртибен расларга.

2. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Министр** **А.М.Сибагатуллин**

Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгының
_________ _____номерлы
боерыгы белән расланган

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫНЫҢ НОРМАТИВ ХОКУКЫЙ АКТЛАРЫНА ҺӘМ НОРМАТИВ ХОКУКЫЙ АКТЛАР ПРОЕКТЛАРЫНА КОРРУПЦИЯГӘ КАРШЫ ЭКСПЕРТИЗА ҮТКӘРҮ ТӘРТИБЕ

## I. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Әлеге Тәртип «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү турында» 17 июль, 2009 ел, 172-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 26 февраль, 2010 ел, 96нчы номерлы карары белән расланган Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү методикасына, «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибенраслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 24.12.2009 ел, 883нче номерлы карарына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының (алга таба – Министрлык) норматив хокукый актларына (алга таба – актлар) һәм норматив хокукый актлар проектларына (алга таба - актлар проектлары) коррупциягә каршы экспертиза үткәрү процедурасын, шул исәптән, Министрлык норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрүне һәм коррупциягә каршы экспертиза бәяләмәләрен исәпкә алуны да кертеп, билгели.

1.2. Акт проектларына коррупциягә каршы экспертиза аларга хокукый экспертиза үткәрелгәндә үткәрелә.

Актларга коррупциягә каршы экспертиза аларның кулланылышына мониторинг ясаганда үткәрелә, шулай ук, Министрлыкның хокукый актларында коррупциоген факторлар булуы турында Министрлыкка мәгълүмат кергән очракта үткәрелә.

1.3. Актларга коррупциягә каршы экспертиза максаты булып актларда һәм актлар проектларында коррупциоген факторларны ачыклап, алга таба аларны бетерү тора.

1.4. Коррупциягә каршы экспертизага кергән актлар һәм актлар проектлары коррупциягә каршы экспертизага кергән норматив хокукый актлар һәм норматив хокукый актлар проектларын исәпкә алу журналында (алга таба – Журнал) теркәлә (әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта).

## II. АКТЛАРГА ҺӘИ АКТЛАР ПРОЕКТЛАРЫНА КОРРУПЦИЯГӘ КАРШЫ ЭКСПЕРТИЗА ҮТКӘРҮ

2.1. Министрлык актларына һәм актлар проектларына коррупциягә каршы экспертизаны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының юридик бүлек мөдире, яисә бүлекнең мөдир вазыйфаларын башкаручы башка хезмәткәре (алга таба – вазыйфаи зат) үткәрә.

2.2. Коррупциягә каршы экспертизаны вазыйфаи зат «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү турында» Федераль законга, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 24.12.2009 ел, 883нче номерлы карары белән расланган Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибенә, әлеге Тәртипкә нигезләнеп, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән Методика буенча үткәрә.

2.3. Коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен актларны һәм актлар проектларын вазыйфаи затка инициативасы буенча (акт проектын әзерләү өчен җаваплы булган) әлеге акт кабул ителгән структур бүлекчә мөдире юллый

2.4. Актларны һәм актлар проектларын коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен Министр да җибәрә ала.

2.5. Коррупциягә каршы экспертиза акт Журналга теркәлгәннән соң ун көн эчендә үткәрелә.

Көчен югалткан яисә гамәлдән чыгарылган норматив хокукый актларга коррупциягә каршы экспертиза үткәрелми.

2.6. Коррупциягә каршы экспертиза ясаганда вазыйфаи зат, кирәк була калса, коррупциягә каршы экспертизага ихтыяҗы булган структур бүлекчәләрдән һәм вазыйфаи затлардан өстәмә материал яисә мәгълүмат соратып алырга хокуклы. Соралган материаллар һәм мәгълүмат вазыйфаи затка запрос алынганнан соң өч көн эчендә бирелергә тиеш.

2.7. Вазыйфаи зат экспертизага бирелгән актта (акт проектында) коррупциоген факторларның булу-булмавын ачыклый.

2.8. Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча әлеге Тәртипнең 2нче кушымтасы формасы белән бәяләмә төзелә. Бәяләмәдә түбәндәге белешмә чагыла:

Экспертизага бирелгән актның реквизитлары (акт проекты атамасы);

акт керү датасы (акт проекты);

экспертиза үткәрелү датасы;

экспертиза үткәрү өчен нигез;

актта (акт проектында) коррупциоген факторларның булу-булмавы;

актның (акт проектының) коррупциоген факторлар булган нигезләмәләре;

коррупция булу мөмкинлеген бетерү өчен хокукый нормаларның формулировкаларын үзгәртү буенча тәкъдимнәр яисә аерым нормаларны төшереп калдыру.

2.9. Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча вазыйфаи зат әзерләгән һәм имзалаган бәяләмә әлеге актны (акт проектын) коррупциягә каршы экспертизага җибәргән затка юллана.

## III. АНТИКОРРУПЦИЯГӘ КАРШЫ ЭКСПЕРТИЗА БӘЯЛӘМӘСЕ БУЕНЧА ЭШ БАШКАРУ

3.1. Коррупциягә каршы экспертизага җибәрелгән актта коррупциоген факторлар ачыкланса, әлеге актны кабул иткән структур бүлекчә җитәкчесе, бәяләмәне алгач, коррупциягә каршы экспертиза предметы булган актка үзгәрешләр кертү, яисә, гамәлдән чыккан итеп тану турында норматив хокукый акт проектын өч көн эчендә әзерләп, коррупциягә каршы экспертиза өчен вазыйфаи затка юллый.

Актка үзгәрешләр кертү турында күрсәтелгән акт проектында коррупциоген факторлар булмаса, әлеге актны кабул иткән структур бүлекчә җитәкчесенә бәяләмә юллана, катнашы булган структур бүлекчә җитәкчеләренең визасы салынган акт проекты Министрга юллана.

3.2. Коррупциягә каршы экспертизага җибәрелгән актта коррупциоген факторлар булмаса, әлеге акт проектын әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчә җитәкчесе, катнашы булган структур бүлекчә җитәкчеләренең визасы салынган акт проектын Министрга юллый яисә актның килештерелү өчен тиешле органнарга һәм оешмаларга юллануын тәэмин итә.

3.3. Коррупциягә каршы экспертизага җибәрелгән актта коррупциоген факторлар ачыкланса, әлеге акт проектын әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчә җитәкчесе, бәяләмәне алгач, өч көн эчендә җитешсезлекләрне бетерергә һәм җиренә җиткереп эшләнгән акт проектын коррупциягә каршы кабат экспертиза үткәрү өчен вазыйфаи затка юллый.

Коррупциягә каршы кабат экспертиза үткәрү вакыты өч көннән артмый.

Яңадан җиренә җиткереп эшләнгән акт проектында коррупциоген факторлар булмаса, вазыйфаи зат бәяләмәне имзалый, һәм акт проекты катнашы булган структур бүлекчә җитәкчеләренең визалары белән, имза кую өчен, Министрга юллана.

Яңадан җиренә җиткереп эшләнгән акт проектында коррупциоген факторлар булган очракта, вазыйфаи зат бәяләмәне Министрга җибәрә. Министр бәяләмәне, бәяләмәдә күрсәтелгән нәтиҗәләрдән чыгып эшләп бетерү өчен структур бүлекчә җитәкчесенә җибәрә.

Структур бүлекчә җитәкчесе өч көн эчендә бөтен кимчелекләрне бетереп, җиренә җиткереп эшләнгән акт проектын, катнашы булган структур бүлекчә җитәкчеләренең визалары белән, имза кую өчен Министрга юллый.

3.4. Коррупциягә каршы кабат экспертиза нәтиҗәләре Журналда чагыла.

## IV. АКТЛАРГА ҺӘИ АКТЛАР ПРОЕКТЛАРЫНА КОРРУПЦИЯГӘ КАРШЫ БӘЙСЕЗ ЭКСПЕРТИЗА ҮТКӘРҮ

4.1. Министрлыкның рәсми рәвештә урнаштырылган норматив хокукый актлары һәм Министрлык әзерләгән һәм мәгълүмати-телекоммуникацион Интернет челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында http://mincult.tatarstan.ru/ (алга таба – сайт) урнаштырылган норматив хокукый актлар проектлары Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза объектлары булып тора.

4.2. Министрлык актларына Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен Министрлыкның акт проектын әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчәсе, юридик бүлеккә акт проектын җибәргән эш көне дәвамында акт проектын, эксперт бәяләмәсе юллана торган адресны (шул исәптән, электрон почта адресын да) күрсәтеп, шулай ук, Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр кабул ителә башлау һәм кабул ителү бетү даталарын күрсәтеп, сайтка урнаштыра.

4.3. Сайтка урнаштырылган актларга Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү срогы биш көннән дә ким түгел.

4.4. Актка (акт проектына) коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча Министрлыкка килгән бәяләмәләр (алга таба - бәяләмә) Татарстан Республикасы Башкарма хакимият органнарының Электрон документ әйләнеше бердәм ведомоствоара системасында теркәлә һәм Министрлыкның актны (акт проектын) әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчәсенә карап чыгу өчен юллана

4.5. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә киңәш рәвешендә була һәм алынганнан соң 15 көн эчендә Министрлык тарафыннан каралырга тиеш. Карау нәтиҗәләре буенча, бәйсез экспертиза үткәргән юридик яки физик затка дәлилләнгән җавап җибәрелә, бәяләмәдә ачыкланган коорупцион факторларны бетерү ысуллары турында тәкъдимнәр булмаган очраклар искәрмә булып тора.

4.6. Актка (акт проектына) коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәргәндә ачыкланган коррупциоген факторларны акт проектын әзерләүче әзерләү стадиясендә бетерә.

4.7. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза бәяләмәсендә бәян ителгән кимчелекләрне бетергәннән һәм тәкъдимнәрне искә алганнан соң, Министрлыкның акт проектын әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчәсе акт проектын, коррупциягә

каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләрне теркәп, кабат кару өчен юридик бүлеккә юллый. Кабат карап чыгу өч көн эчендә башкарыла.

4.8. Актта коррупциоген факторлар ачыкланса, Министрлыкның актны әзерләгән структур бүлекчәсе бәяләмә Министрлыкта теркәлгәннән соң өч көн эчендә актка үзгәрешләр кертү яки аны гамәлдән чыккан дип тану буенча чаралар күрә.

4.9. Министрлык коррупциягә каршы бәйсез экспертизаның Министрлык актларында һәм Министрлык әзерләгән акт проектларында коррупциоген факторлар нәтиҗәләре белән килешмәсә, Министрлык коррупциягә каршы экспертиза өчен әлеге актларны (акт проектларын), коррупциягә каршы бәйсез экспертиза бәяләмәсен һәм үзенең килешмәве нигезләнгән аңлатманы теркәп, законнарда күрсәтелгән тәртиптә Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгына юллый.

4.10. Россия Федерациясе Федераль Җыенның Дәүләт Думасына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон инициативасы тәртибендә керә торган федераль законнар проектларын, Татарстан Республикасы Президенты указлары проектларын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларында коррупциоген факторлар булу турында коррупциягә каршы экспертизаның, шул исәптән, бәйсез экспертизаның нәтиҗәләре белән риза булмаса, әзерләүче норматив хокукый актлары проектларын карау өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертә.

Татарстан Республикасы Мәдәният
министрлыгының норматив
хокукый актларга һәм норматив
хокукый актлар проектларына
коррупциягә каршы экспертиза
үткәрү тәртибенә 1нче кушымта

# КОРРУПЦИЯГӘ КАРШЫ ЭКСПЕРТИЗАГА КЕРГӘН НОРМАТИВ ХОКУКЫЙ АКТЛАР ҺӘМ НОРМАТИВ ХОКУКЫЙ АКТЛАР ПРОЕКТЛАРЫН ИСӘПКӘ АЛУ ЖУРНАЛЫ

| № п/п | Экспертизага акт керү датасы (акт проекты) | Актның атамасы һәм реквизитлары (акт проекты) | Нигезе (проектны эшләүче) | Бәяләмне төзү датасы | Коррупциоген нормалар барлыгы/юклыгы | Бәяләмне алдым | Имза |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |

Татарстан Республикасы Мәдәният
министрлыгының норматив
хокукый актларга һәм норматив
хокукый актлар проектларына
коррупциягә каршы экспертиза
үткәрү тәртибенә 2нче кушымта

**Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә**
**№ ___ ________**

| |
|---|
| |

экспертизага бирелгән актның (акт проекты) исеме һәм реквизитлары

керү датасы __________________
экспертиза үткәрү дата ___________________

экспертиза үткәрү өчен нигез _________________________________________
____________________________________________________________________________

анализланган актта (акт проектында) коррупциоген нормаларның булу-булмавы: ______________________________________________________________________

актның (акт проектының) коррупциоген нормалар табылган нигезләмәләре
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________

коррупционлыкны бетерү өчен хокукый нормаларның формулировкасын үзгәртү, яисә аерым нормаларны бетерү буенча тәкъдимнәр ________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________

Коррупциягә каршы
экспертиза үткәрү өчен
җаваплы зат,
юридик бүлек мөдире ___________________ ____________________

имза Ф.И.ӘИ.